# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 мартында
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында" 2003 елның 6 августындагы 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2011, № 6 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"**7 статья.** "Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы" – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы актларын, шулай ук башка актларны бастырып чыгару өчен билгеләнгән рәсми вакытлы басмасы. "Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы" структурасы, аны әзерләү, чыгару һәм тарату тәртибе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы тарафыннан билгеләнә.";

2) 8 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 9 статьяның беренче өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 11 апреле
№ 29-ТРЗ